**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 июнь № 477

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 февраль, 98 нче, 2015 ел, 3 март, 125 нче, 2015 ел, 2 апрель, 210 нчы, 2015 ел, 22 май, 365 нче, 2015 ел, 20 июнь, 448 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекнең 6.1 пунктында:

«Машиналар һәм җиһазлар җитештерү» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россиядә Хайер суыткычларын җитештерү проекты («ХАЙЕР ЭЛЕКТРИКАЛ ЭППЛАЕНСИС РУС» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).»;

«Башкалар» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чаллы шәһәрендә канализация чистарту корылмалары утырмаларын киптерү һәм пиролизлы эшкәртү комплексын төзү («ИнтерБизнесГруппИнжиниринг» ҖЧҖ, Мәскәү шәһәре).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\477.docx